КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 18 июнь г.Казань № 501

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Оешмалар мөлкәтенә салым түләүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен махсус икътисадый зоналарның идарә итүче компанияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 20 май, 414 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Оешмалар мөлкәтенә салым түләүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен махсус икътисадый зоналарның идарә итүче компанияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 20 май, 414 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «2014 – 2021» саннарын «2014 – 2024» санына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Оешмалар мөлкәтенә салым түләүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен махсус икътисадый зоналарның идарә итүче компанияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

2 пунктка Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацияле икътисады» дәүләт программасының «2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасында дәүләт икътисадый сәясәтен камилләштерү» ярдәмче программасы кысаларында» сүзләрен өстәргә;

4 пунктта:

беренче абзацта «исәпләнгән һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"N – салым ставкасы.»;

6 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«үзгәртеп кору, бетерү процессында тормый, субсидия алучыга карата банкротлык процедурасы кертелмәгән, эшчәнлек Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган;»;

7 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Килешүдә субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше, субсидия, күчерү сроклары һәм тәртибе, субсидия күчерелә торган счетлар, субсидия бирү нәтиҗәләренең мәгънәләре, өстәмә хисап бирү сроклары һәм формалары, субсидияне кире кайтару очраклары, тәртибе һәм сроклары, субсидия алучының Министрлык һәм дәүләт финанс тикшерүе органнары тарафыннан субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшерү өчен ризалыгы, әлеге Тәртип һәм төзелә торган килешү шартларын үтәү турында нигезләмәләр, кабул ителгән йөкләмәләрне үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен субсидия алучының җаваплылыгы, шул исәптән субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен бозган өчен штраф санкцияләре күздә тотыла.»;

8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Субсидия бирү нәтиҗәсе булып, инвестицияләр күләменең еллык үсеш темпы, шул исәптән махсус икътисадый зона резидентлары тарафыннан гамәлгә ашырылган, субсидия алучы идарәсендә җыелган тупланган нәтиҗә белән капитал салулар тора.

Субсидия алучы Министрлыкка әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта нигезендәге форма буенча хисап елыннан соң килүче елның 1 июненнән дә соңга калмыйча субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисап бирә.»;

9 пунктта:

«а» пунктчасының өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия алучы үзгәртеп кору, бетерү процессында тормый, аңа карата банкротлык процедурасы кертелмәгән, эшчәнлек Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган;»;

«б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) хисап чоры тәмамланганнан соң, узган салым чорыннан соң килүче елның 20 апреленнән дә соңга калмыйча оешма мөлкәтенә салым буенча субсидия алучының җитәкчесе һәм баш хисапчысы тарафыннан имзаланган, әлеге Тәртипкә 2 нче кушымта нигезендә форма буенча белешмә-хисап, салым чоры тәмамлангач, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча оешмалар мөлкәтенә салым буенча салым декларациясе, салым органы тарафыннан телекоммуникацион элемтә каналлары буенча салым декларациясен җибәрүне һәм кабул итүне раслаучы квитанция һәм белдерү кәгазе;»;

13 пунктта «(салым исәпләве)» сүзләрен төшереп калдырырга;

15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Бирелгән субсидия түбәндәге очраклрада Министрлыкның тиешле таләбе алынган көннән алып, эш көннәрендә исәпләнелә торган 10 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш:

субсидия алу өчен дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар бирү фактын билгеләү;

Министрлык һәм дәүләт финанс тикшерүенең вәкаләтле органы тарафыннан тикшерү фактлары буенча ачыкланган субсидия биргәндә куелган шартларны бозу;

субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешмәүләр;

субсидияләр бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисап тапшырмау;

әлеге Тәртиптә каралган срокта хисап чоры тәмамланганнан соң, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча оешмалар мөлкәтенә салым буенча салым декларациясе, салым органы тарафыннан телекоммуникацион элемтә каналлары буенча салым декларациясен җибәрүне һәм кабул итүне раслаучы квитанция һәм белдерү кәгазен тапшырмау.»;

түбәндәге эчтәлекле $15^1$ пункт өстәргә:

«$15^1$. Субсидия алучы субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешмәгән өчен штраф санкцияләре кулланыла.

Штраф санкцияләре күләме (А) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$A = (1 - \frac{d}{D}) \times X \times V,$$

монда:

d – субсидия бирү турындагы килешүне үтәү срогы тәмамланган көнгә субсидия бирү нәтиҗәсенең ирешелгән күрсәткече;

D – субсидия бирү нәтиҗәсенең пландагы әһәмияте;

X – хисап чорының соңгы көненә Россия Федерациясе Үзәк банкының өч йөзлек төп ставкасының берсенә тигез корректлау коэффициенты;

V – субсидия алучыга бирелгән субсидия күләме.»;

күрсәтелгән Тәртипкә 1 һәм 2 нче кушымталар өстәргә (теркәлгәннәр).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин